ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

20 гыйнвар 2026ел № 301

Җир участогын сатуларда арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Җир участогын сатуларда арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Башкарма комитет Карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Җир участогын сатуларда арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3671 номерлы;

2) «Җир участогын сатуларда арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 июнендәге 2824 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 20 гыйнварындагы
301 номерлы карарына
кушымта

Җир участогын сатуларда арендага,
милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) муниципаль милектәге җир участогын сатуларда бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик затлар (шул исәптән шәхси эшмәкәрләр) һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә гариза бирүче тарафыннан вәкаләтләнгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) якларга мөмкин.

3. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла торган гариза бирүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш.

II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

Муниципаль хезмәтнең исеме

4. Җир участогын сатуларда арендага, милеккә бирү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме

5. Муниципаль хезмәтне Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба – Башкарма комитет) күрсәтә .

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) җир участогын арендалау шартнамәсе (алга таба - аренда шартнамәсе);

2) җир участогын сату-алу шартнамәсе (алга таба - сату-алу шартнамәсе);

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (Регламентка 4 нче кушымта).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе сыйфатында реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе, гариза бирүченең сайлавы буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризада (Регламентка 7 нче кушымта) күрсәтелгән ысул белән җибәрелә.

7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, Башкарма комитет вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Гариза бирүченең сайлавы буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән электрон документның, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәренең имзасы белән расланган, кәгазьдә бастырып чыгарылган нөсхәсе формасында КФҮдә алынырга мөмкин.

9. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен, электрон документ формасында яки электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы

10. Республика порталы ярдәмендә, Башкарма комитетка, КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы, гариза бирүченең категориясенә (билгеләренә) бәйсез рәвештә, 34 эш көне тәшкил итә.

11. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.

12. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ формасында җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитетта һәм КФҮдә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

13. Түбәндәге нигезләр булганда, гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет кабул итә:

1) Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән документлар тапшырылмау;

2) законлы вәкилләр турында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган мәгълүматлар расланмау, гариза бирүче исеменнән гариза (запрос) аңа вәкаләт бирелмәгән зат тарафыннан бирелү;

3) документлар тиешле булмаган органга тапшырылу;

4) дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар, алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр булган документлар, үз көчен югалткан документлар тапшырылу;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булып тормаган зат мөрәҗәгать итү;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

7) электрон формадагы гариза (запрос) һәм башка документлар, гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган;

8) электрон документлар аларны бирү форматларына карата таләпләргә туры килми һәм (яки) укылмый.

14. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр:

Башкарма комитетка җир участогының урнашу схемасын раслау турында гариза кергән вакытка Башкарма комитетның карап тикшерүендә җир участогын урнаштыруның башка зат тарафыннан элегрәк тапшырылган схемасы булган һәм барлыкка китерү әлеге схемаларда каралган җир участокларының урнашу урыны өлешчә яки тулысынча туры килгән очракта, Башкарма комитет җир участогының урнашу схемасын раслау турында соңрак бирелгән гаризаны карап тикшерүне туктату турында карар кабул итә һәм мондый карарны гариза бирүчегә җибәрә.

Җир участогының урнашу схемасын раслау турында соңрак бирелгән гаризаны карап тикшерү, җир участогын урнаштыруның элегрәк җибәрелгән схемасын раслау турында карар кабул ителгәнгә кадәр яисә җир участогын урнаштыруның элегрәк җибәрелгән схемасын раслаудан баш тарту турында карар кабул ителгәнгә кадәр туктатыла.

15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) җир участогының чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон таләпләре нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;

2) җир участогына дәүләт яки муниципаль милек хокукы теркәлмәгән, мондый җир участогы дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яисә җир участогыннан барлыкка килгән очраклардан тыш;

3) җир участогына карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрлары билгеләнмәгән, җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаган очраклардан тыш;

4) җир участогына карата җир участогының шәһәр төзелеше планы юк, әгәр җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаган очраклардан тыш;

5) җир участогына карата карата рөхсәт ителгән файдалану билгеләнмәгән яки җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану аукцион үткәрү турында гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатларына туры килми;

6) җир участогы тулысынча, җир участогыннан файдалану буенча билгеләнгән чикләүләр, аукцион үткәрү турында гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогыннан файдалану мөмкинлеге бирми торган территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан;

7) җир участогы җирләрнең билгеле бер категориясенә кертелмәгән;

8) җир участогы даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп алу яки аренда хокукында бирелгән;

9) җир участогында гражданнарга яисә юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, аларны урнаштыру сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки РФ Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан очраклардан тыш, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, тәмамланмаган төзелеш объектына карата рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул ителгән яисә билгеләнгән таләпләр нигезендә рөхсәтсез корылманы сүтү яки күрсәтелгән карарлар белән билгеләнгән срокларда аны тәртипкә китерү буенча Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 11 өлештә билгеләнгән йөкләмәләр үтәлмәгән җир участогын бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш;

10) җир участогында дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан, һәм күрсәтелгән бинаны, корылманы, төзелеше тәмамланмаган объектны арендага бирү яки сату яки арендага бирү башка аукцион предметы булып тора яисә күрсәтелгән бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект бу аукционда җир участогы белән бер үк вакытта сатылмый яки арендага бирелми, җир участогында сервитут, җәмәгать сервитуты нигезендә урнаштыру рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки әлеге Кодексның 39.36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар урнашкан очраклардан тыш;

11) җир участогы әйләнештән алынган, федераль закон нигезендә әйләнештән алынган җир участоклары аренда шартнамәсе предметы булырга мөмкин булган очраклардан тыш;

12) җир участогы әйләнештә чикләнгән, җир участогын арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү очрагыннан тыш;

13) җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган, җир участогын резервлау срогыннан артмаган срокка җир участогын арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрүочрагыннан тыш;

14) җир участогы аны комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан яки аны тормышка ашыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат тарафыннан тәэмин ителә торган территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән;

15) җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән;

16) җир участогы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы яки региональ инвестицион программа нигезендә бина яки корылма урнаштыру өчен билгеләнгән;

17) җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән;

18) җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында гариза яисә җир участогы бирү турында гариза кергән, мондый җир участогын бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очраклардан тыш;

19) җир участогы гомуми файдаланудагы җир участогы булып тора яки гомуми файдаланудагы җирләр, гомуми файдаланудагы территория чикләрендә урнашкан;

20) җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган, мондый җир участогында урнашкан, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йорт дип тану сәбәпле, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участокларыннан тыш.

16. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр, гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

17. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

18. Муниципаль хезмәттән файдалануга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

19. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел.

Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы

20. КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирелгән көнне гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәү номеры һәм гариза бирү датасы белән КФҮнең Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан (алга таба - КФҮ АМС) өземтә бирелә.

21. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм портал, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүне раслаучы белдерү кәгазе ала.

22. Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, ике нөсхәдә гариза бирелгән көнне бер нөсхә, гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү датасын күрсәтеп, Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр

23. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

24. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында тәэмин ителә:

1) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (биналарга/биналардан уңайлы керү/чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү);

2) гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

5) аларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, инвалидларның хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;

6) ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктал Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н Боерыгы белән билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, юл күрсәтүче этне кертү.

25. Инвалидлар өчен муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга керү һәм Регламентның 23 пунктының 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган чаралардан файдалануны тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

26. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр турындагы мәгълүмат шәһәрнең, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре

27. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм бирү башкарыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләр булу;

шәһәренең рәсми сайтында, мәгълүмат стендларында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга хезмәтләрдән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

28. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) Башкарма комитетның вазыйфаи затлары тарафыннан Регламентны бозуга нигезле шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

КФҮдә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь нөсхәсе формасында алу кирәк булган очракта бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләргә хокуклы.

29. Муниципаль хезмәтне гариза бирүчеләрнең ихтыяҗларына туры килүгә тикшерү кире элемтәне анализлау нигезендә даими үткәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү процессларын оптимальләштерү гариза бирүчеләрнең муниципаль хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе тотрыклы рәвештә кимегән (рәттән өч айдан артык) очракта үткәрелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимемәгән очракта, оптимальләштерү кимендә биш елга бер тапкыр үткәрелә.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы һәм статусы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.

31. Муниципаль хезмәт күрсәтү экстерриториаль принцип буенча, яшәү урынына яки фактта яшәү (тору) урынына бәйсез рәвештә, гариза бирүченең сайлавы буенча теләсә кайсы КФҮдә гамәлгә ашырыла.

32. Гариза бирүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен комплекслы запрос составында алырга мөмкин.

33. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре турында мәгълүмат Яр Чаллы шәһәренең, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә карата башка таләпләр

34. Муниципаль хезмәт электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче хокуклы:

1) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 7.2 пункты нигезендә элек электрон рәвешләре таныкланган документларны һәм мәгълүматны бирергә;

3) электрон формада бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы һәм статусы турында мәгълүматлар алырга;

4) Бердәм портал, Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

35. Гаризаны формалаштыру, гаризаны нинди дә булса башка формада өстәмә рәвештә бирмичә, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

36. Гариза бирүчеләрнең КФҮгә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчегә, КФҮдә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә, кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге датага кадәр бер тәүлек алдан тәмамлана.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, гариза бирүчегә системада сорала торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләге буенча);

кабул итүне теләгән көн һәм вакыт.

Алдан язылу вакытында гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүматлар шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, гариза бирүчегә раслау талоны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан 15 минут узуга ул килмәгән очракта алдан язылу гамәлдән чыгарылу турында гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Гариза бирүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәкле мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

37. Җир участогының урнашу схемасын электрон документ формасында әзерләү «Милли киңлек мәгълүматлары системасы» бердәм цифрлы платформасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

38. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында, түбәндәгеләргә бүлеп, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

39. Гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның формалары турында мәгълүматлар Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары

Административ процедуралар исемлеге

40. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документларны кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

41. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен «Бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати запросларны җибәрергә кирәк:

1) «Сорала торган җир участогы турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос,

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә, Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенә җибәрелә. Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара запрос җибәрелгән вакыттан башлап ике эш көненнән артмаган срокта бирә;

2) «Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә, Федераль салым хезмәтенә җибәрелә. Федераль салым хезмәте соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара запрос җибәрелгән вакыттан башлап биш эш көненнән артмаган срокта бирә. Запрос хезмәт күрсәтүне сорап юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) «Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә, Федераль салым хезмәтенә җибәрелә. Федераль салым хезмәте соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара запрос җибәрелгән вакыттан башлап биш эш көненнән артмаган срокта бирә. Запрос хезмәт күрсәтүне сорап шәхси эшмәкәр мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла.

42. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка сервислар ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати запросларны җибәрергә кирәк:

1) «Гариза бирүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» мәгълүмати запросы. Муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән мәгълүмати запрос «Бердәм дәүләт гражданнар хәле актларын теркәү реестры» сервисы яисә «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә, бер эш көненнән артмаган срокта тормышка ашырыла;

2) «Ышаныч язуы бирү факты һәм аның эчтәлеге турында мәгълүматлар» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос «Бердәм нотариат мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә, ике эш көненнән артмаган срокта тормышка ашырыла;

3) «Җир участогы бирү өчен чикләүләр булу турында яки булмау турында (шул исәптән территориаль зона, кызыл линия чикләре, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар булу, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары турында) бәяләмә» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос биш эш көненнән артмаган соракта Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсеннән соратып алына;

4) «Тоташтыруның техник шартлары турында мәгълүматлар» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос биш эш көненнән артмаган соракта инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмалардан соратып алына.

IV. Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны карап тикшерү статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

43. Гариза бирүчегә, аның муниципаль хезмәт күрсәтүгә запросының Регламентта билгеләнгән статусы үзгәрү турында (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карап тикшерү турында; муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән этабында башкарырга

тиешле адымнары һәм гамәлләре турында, техник мөмкинлек булганда, түбәндә санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

- смс-мәгълүмат бирү ярдәмендә;
- Бердәм портал ярдәмендә;
- Республика порталы ярдәмендә;
- башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

1 нче кушымта

ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТУЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) - Республика порталы;
2. Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:// www.gosuslugi.ru/) - Бердәм портал;
3. «Федераль дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) - Реестр;
4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты - Башкарма комитет;
5. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ;
6. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы — КФҮ АМС.

2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

№	Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе	Гариза бирүченең аерым билгесе исеме	Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы
1.	Аукцион үткәрү турында карар	Физик зат	1А
2.		Юридик зат	2А
3.		Шәхси эшмәкәр	3А
4.		Гариза бирүченең вәкиле	4А

3 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен
кирәкле документларның тулы исемлеге

№	Идентификатор	Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең расшифровкасы, төркемнән документлар саны	Тапшыру ысулы
Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар			
1.	1А-4А	Гариза	Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ
2.	1А-4А	Шәхесне раслаучы документ	Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ
3.	4А	Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ	Башкарма комитет, КФҮ
Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар			
1.	1А-4А	Җир участогының урнашу схемасы (чикләрендә җир участокларын яңадан бүлү гамәлгә ашырыла торган территорияне межалау проекты булмаган очракта мәҗбүри)	Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ
2.	1А-4А	Хокук билгеләүче документларның күчермәләре, әгәр хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса	Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ

4 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту һәм
гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны
кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

№	Идентификатор	Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документлар төрләренең расшифровкасы, төркемнән документлар саны
Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр		
1.	1А-4А	җир участогының чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон таләпләре нигезендә төгәлләштерелергә тиеш
2.	1А-4А	җир участогына дәүләт яки муниципаль милек хокукы теркәлмәгән, мондый җир участогы дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яисә җир участогыннан барлыкка килгән очраклардан тыш
3.	1А-4А	җир участогына карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрлары билгеләнмәгән, җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаган очраклардан тыш
4.	1А-4А	җир участогына карата җир участогының шәһәр төзелеше планы юк, әгәр җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә биналар, корылмалар төзү мөмкинлеге каралмаган очраклардан тыш
5.	1А-4А	җир участогына карата карата рөхсәт ителгән файдалану билгеләнмәгән яки җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану аукцион үткәрү турында гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатларына туры килми
6.	1А-4А	җир участогы тулысынча, җир участогыннан файдалану буенча билгеләнгән чикләүләр, аукцион үткәрү турында гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә җир участогыннан файдалану мөмкинлеге бирми торган территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан;
7.	1А-4А	җир участогы җирләрнең билгеле бер категориясенә кертелмәгән
8.	1А-4А	җир участогы даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп алу яки аренда хокукында бирелгән
9.	1А-4А	җир участогында гражданнарга яисә юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты

		урнашкан, аларны урнаштыру сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки РФ Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан очраклардан тыш, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, тәмамланмаган төзелеш объектына карата рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул ителгән яисә билгеләнгән таләпләр нигезендә рөхсәтсез корылманы сүтү яки күрсәтелгән карарлар белән билгеләнгән срокларда аны тәртипкә китерү буенча Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 11 өлештә билгеләнгән йөкләмәләр үтәлмәгән җир участогын бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш
10.	1А-4А	җир участогында дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан, һәм күрсәтелгән бинаны, корылманы, төзелеше тәмамланмаган объектны арендага бирү яки сату яки арендага бирү башка аукцион предметы булып тора яисә күрсәтелгән бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект бу аукционда җир участогы белән бер үк вакытта сатылмый яки арендага бирелми, җир участогында сервитут, җәмәгать сервитуты нигезендә урнаштыру рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки әлеге Кодексның 39.36 статьясы нигезендә урнаштырылган объектлар урнашкан очраклардан тыш
11.	1А-4А	җир участогы әйләнештән алынган, федераль закон нигезендә әйләнештән алынган җир участоклары аренда шартнамәсе предметы булырга мөмкин булган очраклардан тыш
12.	1А-4А	җир участогы әйләнештә чикләнгән, җир участогын арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү очрагыннан тыш
13.	1А-4А	13) җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган, җир участогын резервлау срогыннан артмаган срокка җир участогын арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрүочрагыннан тыш
14.	1А-4А	җир участогы аны комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан яки аны тормышка ашыру Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат

		тарафыннан тәэмин ителә торган территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән
15.	1А-4А	җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән
16.	1А-4А	җир участогы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы яки региональ инвестицион программа нигезендә бина яки корылма урнаштыру өчен билгеләнгән
17.	1А-4А	җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән
18.	1А-4А	җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында гариза яисә җир участогы бирү турында гариза кергән, мондый җир участогын бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очраклардан тыш
19.	1А-4А	җир участогы гомуми файдаланудагы җир участогы булып тора яки гомуми файдаланудагы җирләр, гомуми файдаланудагы территория чикләрендә урнашкан
20.	1А-4А	җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган, мондый җир участогында урнашкан, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йорт дип тану сәбәпле, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участокларыннан тыш
Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр		
1.	1А-4А	Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән документлар тапшырылмау
2.	1А-4А	Законлы вәкилләр турында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган мәгълүматлар расланмау, гариза бирүче исеменнән гариза (запрос) аңа вәкаләт бирелмәгән зат тарафыннан бирелү
3.	1А-4А	Документлар тиешле булмаган органга тапшырылу
4.	1А-4А	Дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар, алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр булган документлар, үз көчен югалткан документлар тапшырылу

5.	1А-4А	Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булып тормаган зат мөрәҗәгать итү
6.	1А-4А	Гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булу

5 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Аукцион үткәрү турында карар
_______________ № ____

Сезнең ____________ №________ мөрәҗәгатегезгә ______________________ Башкарма комитеты хәбәр итә.

Сезнең тарафтан соралган кадастр номеры _______________, мәйданы _____ булган, ______________________________________ адресы буенча урнашкан, җирләр категориясе_____________, рөхсәт ителгән файдалану төре __________________________ булган җир участогы сату буенча аукцион формасында (аренда хокукы/милек хокукы) үткәрелә торган сатуларда сатылачак.

Гаризалар кабул итүнең тәмамлану датасы ________, аукцион датасы ___________.

Аукционда катнашу өчен Сезгә тиешле заявка бирергә кирәк.

Гаризаларны кабул итү/бирү урыны __________________.

Сатуларны оештыручы ___________________, башлангыч бәя _________, аукцион адымы ___________, задатокның күләме _____________, задатокны кертү һәм кире кайтару тәртибе _______________, өстәмә мәгълүмат ________________________________.

______________________	______________________________
(вазыйфа)	(имза, фамилия, инициаллар)

Регламентка
6 нчы кушымта

(Башкарма комитет бланкы)

Белдерү кәгазе

____ мөрәҗәгать итү сәбәпле,
(гариза бирүченең – физик затның Ф.И.А.и., юридик затның исеме)

гариза № ________ ________ ________ ________ ел, __________________________ турында

____

____

____ нигезендә,

тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, түбәндәге сәбәпләр нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Вазыйфаи зат (Ф.И.А.и.)

____
(Башкарма комитетның
карар кабул итүне гамәлгә ашыра
торган вәкаләтле затының
имзасы)

Башкаручы (Ф.И.А.и.)

____
(башкаручы белән элемтә)

Регламентка
7 нче кушымта

____
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

____
(физик затлар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

____
(юридик затлар өчен – исеме, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛ, ОГРНда дәүләт теркәве турында мәгълүматлар)

____
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Җир участогын сатуларда арендага / милеккә бирү турында
гариза

Сездән аукцион үткәрү юлы белән җир участогын арендага / милеккә бирүне сорыйм.

_____________ муниципаль район (шәһәр округы), _______________ торак пункт _______________ урамы _______________ йорт _____ адресы буенча урнашкан, мәйданы __________ кв. м., кадастр номеры ___________:___, рөхсәт ителгән файдалану төре белән _____________ , _______________ категориясендәге җирләрдән булган җир участогы

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) ____

2) ____

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирүне сорыйм:

[ ] Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

[ ] Башкарма комитетка кәгазь документ формасында;

[ ] Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәгендә кәгазь документ формасында.

______________ ______________ (______________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

8 нче кушымта

(Башкарма комитет бланкы)

Белдерү кәгазе

____ мөрәҗәгать итү сәбәпле,
(гариза бирүченең – физик затның Ф.И.А.и., юридик затның исеме)

гариза № ________ ________ ________ ________ ел, ________________________ турында

____

____

____ нигезендә,

тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, түбәндәге сәбәпләр нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Вазыйфаи зат (Ф.И.А.и.)

____
(Башкарма комитетның карар кабул итүне гамәлгә ашыра торган вәкаләтле затының имзасы)

Башкаручы (Ф.И.А.и.)

____
(башкаручы белән элемтә)